КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 ноябрь г.Казань № 1211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 438 нче карары белән расланган Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 ел, 8 июнь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июль, 728 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Табигый һәм техник фәннәр өлкәсендә балаларга өстәмә белем бирү тармагындагы чараларны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә коммерциячел булмаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«6. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле

финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин